| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА<br>И ПРОДОВӨЛЬСТВИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ<br>ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05. 04. 2016 г.Казань № 69/2-пр

2016 елга авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына федераль бюджеттан килә торган акчалар хисабыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 15 июлендәге “2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорда авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы турында” № 598 карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 06 октябрендәге “2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорда авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасын тормышка ашыру турында” № 724 карарын үтәү максатларында боерык бирәм:

1. Кушымтага туры китереп, 2016 елга авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына федераль бюджеттан килә торган акчалар хисабыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
05.04.2016 № 69/2-пр
боерыгына карата кушымта

2016 елга авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту очен Татарстан Республикасы мунициипаль берәмлекләре бюджетларына федераль бюджеттан килә торган акчалар хисабыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2016 елга авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына федераль бюджеттан килә торган акчалар хисабыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр муниципаль берәмлекләрнең бюджетларына гражданнарның, яшь гаиләләрнең һәи яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту буенча чараларны тормышка ашыруга бәйле булган чыгым хәлләрен софинанслау максатларында бирелә.

3. Субсидияләр муниципаль берәмлекләрнең бюджетларына түбәндәге шартларда бирелә:

а) шушы тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны күздә тотучы муниципаль программаның булуы;

б) муниципаль берәмлекнең субсидияләр бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәү өчен кирәкле булган күләмнәрдә түбәндәгеләрне җәлеп итүе:

гражданнарның, яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең үз (бурычка алган) акчалары булу – соңиаль түләүләр бирелгән очракта;

эш бирүчеләрнең акчалары – торак бинаның найм шартнамәсе буенча яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә бирелә торган торак төзелеше (торакны сатып алу) буенча мунициипаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен софинанслауга карата субсидияләр бирелү очрагында;

в) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган рәвешләрдә торак бинаның найм шартнамәсе буенча чараларда катнашучыларның – социаль түләүләрне алучыларның һәм торак алучыларның беренчел исемлекләре булу.

4. Муниципаль берәмлек бюджетына субсидиянең күләме торак бинаның найм шартнамәсе буенча чараларда катнашучыларның – социаль түләүләрне алучыларның һәм торак алучыларның беренчел исемлекләре нигезендә билгеләнә.

5. Субсидияләр мунициипаль берәмлекләрнең бюджетларына бюджет акчалары кергәннән соң 10 көннән дә соцга калмыйча төзелгән килешү нигезендә бирелә, алар түбәндәгеләрне күздә тота:

а) субсидиянең күләме һәм максатчан билгеләнеше турында мәгълүматлар;

б) җирле бюджетта каралган һәм бюджетныкы булмаган чыганаклардан алына торган акчаларның күләме турында мәгълүматлар;

в) җирле үзидарә органы (муниципаль берәмлек органы) тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) Министрлык раслый торган рәвешләрдә һәм вакытларда торак бинаның найм шартнамәсе буенча чараларда катнашучыларның – социаль түләүләрне алучыларның һәм торак алучыларның расланган җыелма исемлекләрен тапшыруы турында йөкләмә;

г) субсидияне бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләренең мәгънәсе;

д) җирле үзидарә органының (муниципаль берәмлек органының) түбәндәгеләрне тапшыру йөкләмәсе:

Федераль дәүләт статистика хезмәте раслый торган федераль статистика күзәтүе рәвешендә гражданнарның, яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту буенча чараларны тормышка ашыру барышы турында белешмәләрне;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия санала торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары турында Министрлык тарафыннан раслана торган вакытта һәм рәвештә хисапларны;

е) якларның килешүе буенча билгеләнә торган шартлар.

Субсидияне бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бюджет йокләмәләре лимиты булмау;

торак бинаның найм шартнамәсе буенча чараларда катнашучыларның – социаль түләүләрне алучыларның һәм торак алучыларның беренчел исемлекләре булмау.

6. Килешүнең рәвеше Министрлык тарафыннан раслана.

7. Министрлык бюджет акчаларын төп бүлүче булып санала һәм Министрлыкка бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнгән тәртиптә 10 эш көне дәвамында Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан муниципаль районнарның башкарма комитетларының лицевой счетларына акчаларны күчерә.

8. Субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге ел саен Министрлык тарафыннан субсидияләрне бирү буенча түбәндәге нәтиҗәлелек күрсәткечләре нигезендә бәяләнә:

а) 2014-2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорда авыл территорияләрен тотрыклы үстерү” федераль максатчан программасы (алга таба – Программа) кысаларында торак кертүнең (сатып алуның) гомуми күләме;

б) Программа кысаларында яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр өчен торак кертү (сатып алу) күләме;

в) Программа кысаларында торак шартларын яхшыртучы гаиләләрнең гомуми саны;

г) Программа кысаларында торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең гомуми саны.

9. Агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидияләр субсидияләрне биргән елдан соң килүче елның 1 декабренә кадәр федераль бюджет керемена кайтарып бирелергә тиеш.

Министрлыкның агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидияләргә мохтаҗлык булу турындагы карары нигезендә күрсәтелгән субсидияләрнең калган өлешеннән артып китмәгән күләмдәге акчалар чираттагы финанс елында элек алар бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты керемена, муниципаль берәмлек бюджетының күрсәтелгән субсидияләрне бирү максатларына ярашлы булган чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен кайтарып бирелергә мөмкин.

Әгәр дә субсидияләрнең калган өлеше Россия Федерациясе бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгели торган тәртиптә Россия Федерациясе бюджеты керемена түләттерелергә тиешле була.

10. Шушы Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет керемена ирекле кайтарып бирүдән баш тарткан очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри түләттерелергә тиешле була.

11. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары муниципаль берәмлекләргә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

12. Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге, бюджет акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өчен җирле үзидарә органнары (муниципаль берәмлек органнары) җаваплы итеп билгеләнә.

13. Субсидияләр, аннан максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган очракта, Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә федераль бюджет керемена түләттерелергә тиешле була.

14. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.